СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

31.05.201 Алабуга шәһәре № 367

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2012 елның 13 июлендә чыккан 230 номерлы «Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга шәхси торак төзелеше, дача төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт яны җир участогы), бакчачылык яки яшелчәчелек өчен бушлай җир кишәрлекләре бирү нормаларын билгеләү турында » карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32, 32.1, 34 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2012 елның 13 июлендә чыккан 230 номерлы «Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга шәхси торак төзелеше, дача төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт яны җир участогы), бакчачылык яки яшелчәчелек өчен бушлай җир кишәрлекләре бирү нормаларын билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карар исемендә «дача төзелеше» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җир кишәрлекләрен бирүгә (тапшыру) гариза язганда 18 яше тулмаган өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, шул исәптән үги балалары, шулай ук уллыкка (кызлыкка) һәм опекага алынган (аларга карата опека һәм попечительлек вакыты чикләнмәгән яисә балигъ булган вакытка кадәр гамәлгә ашырыла) гражданнарга бушлай җир кишәрлекләре бирү нормаларын билгеләргә:

2.1. җир кишәрлекләренең иң аз күләме:

- аукционнан башка шәхси торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен - 0,08 гектар, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруга (йорт яны җир участогы) -- 0,15 га мәйдан, бакчачылык яки яшелчәлек өчен - 0,15 га мәйдан;

2.2. җир кишәрлекләренең иң чик күләме: